Azatlıq Radiosı

ЯҢАЛЫКЛАР

# Дроннар Башкортстанда нефть куган "Сөбханкол" диспетчер станциясенә һөҗүм иткән булуы ихтимал

әле генә




Exilinova фотосы

**Ул Туймазы районында урнашкан**

**Дроннар Башкортстанда нефть куган "Сөбханкол" диспетчер станциясенә һөҗүм иткән булуы ихтимал.**


Supernova+ украин каналы кара төтен күтәрелгән видеолар чыгарды.

Соңрак республиканың гадәттән тыш хәлләр идарәсе сәнәгать корылмасына террор һөҗүме ясалуын хәбәр итте, әмма кайсы ширкәткә ясалуы турында мәгълүмат булмады.

Диспетчер станциясе Русиянең Башкортстандагы Туймазы районында урнашкан нефть эшләнмәләре үткәргечләре системының стратегик корылмасы. Ул нефтьне кабул итү, саклау һәм кудыруны тәэмин итүче "Транснефть-Урал" ширкәтенә карый. Станция Сөбханкол авылы янында урнашкан.

Azatlıq Radiosı | Азатлык Ради...

Azatlıq Radiosı | Азатлык Радиосы
Дроннар Башкортстанда нефть куган ...




23 июльдә Башкортстанның Туймазы районы Сөбханкол авылы тирәсендәге һәм Сембер өлкәсе Яңа Спас районындагы нефть ширкәтләренә һөҗүм булды

Төбәкләр хакимиятләре һөҗүмнәрне раслады, ләкин кайсы объектларга эләгүе турында төгәл әйтмәде.

Укарина ягыннан аңлатма юк.

Astra телеграм каналының OSINT тикшерүе һөҗүмнең Башкортстанда Сөбханкол нефть җыю, саклау һәм кудыру станциясенә һәм Сембер өлкәсендә Яңа Спас нефть эшкәртү ширкәтенә булуын күрсәтә.

🔥 1

48 👁 Jul 23 at 12:13

Иртә белән Башкортстанда дроннар һөҗүме куркынычы игълан ителде. Уфада һава аланы очкычларны вакытлыча кабул итмәде һәм җибәрмәде.

Украина стратегик ширкәтләргә дроннарны Русия һөҗүмнәренә җавап итеп җибәрә. Киев Русиянең һәр нефть эшкәртү корылмасына ясалган һөҗүм Мәскәүнең Украинага каршы сугыш алып бару мөмкинлеген киметә дигән фикердә.

**🛑 Русиядә Азатлык сайты томаланды, нишләргә? Безнең кулланма.**
**🌐 Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

---

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар саклanган